МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

06.09.2017 № 499

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибен раслау турында**

“Коррупциягә каршылык турында” 2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ Федераль законының 9 нчы мәкаләсенә туры китереп, б о е р а м:

1. Боерыкка кушылган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.
2. Биредәге боерыкны министр урынбасарларына, министрлыкның структурчыл бүлекләренең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.
3. Биредәге боерыкны башкару контролен министр урынбасары О.А. Степущенкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

2017 ел 6 нчы сентябрь № 499
Татарстан Республикасы Гражданнар
оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш
хәлләр министрлыгы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибе (алга таба – Тәртип) “Коррупциягә каршылык турында” 2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ Федераль законының 9 нчы мәкаләсенең 5 нче бүлегенә туры китереп төзелде.

2. Тәртип Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында (алга таба – Министрлык) яллаучы вәкиле буларак Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының (алга таба – министр) Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән үзләренә мөрәҗәгать итү факты турында белдерү регламентын билгели.

3. Коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү фактлары турында белдерү, бу фактлар буенча тикшерү үткәрелгән яисә үткәрелә торган очракларны санамаганда, гражданлык хезмәткәренең вазифа (хезмәт) бурычы булып тора.

4. Коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында министрны белдерүне (алга таба – Белдерү) гражданлык хезмәткәре Тәртипнең 1 нче кушымтасына карата язу формасында төзи.

Белдерүдә түбәндәге мәгълүматлар язылырга тиеш:

Белдерүне юнәлткән шәхеснең фамилиясе, исеме, атасының исеме, урнашкан вазифасы һәм структура бүлекчәсе, тору урыны һәм телефоны;

коррупция җинаятьләренә күндерә торган физик (юридик) шәхес турында барлык билгеле мәгълүматлар;

гражданлык хезмәктәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән кайсыдыр шәхесләрнең хезмәт бурычларын гражданлык хезмәктәре башкару белән бәйле Министрлыкның гражданлык хезмәктәренә булган мөрәҗәгать итү фактының (беленгән очраклары) шартларының тасвиры (датасы, урыны, вакыты, башка шартлары);

гражданлык хезмәткәренә килгән коррупция җинаятен эшләүгә күндерү турында күрсәтә торган мөрәҗәгатьнең (хезмәткәр ягына шәхес эшләгән хәрәкәтнең, тәкъдимнең, гаризаның, таләпнең, башка формадагы мөрәҗәгатьнең) җентекле тасвиры, шулай да гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятен эшләүгә күндерү билгеләреннән торган эшләрнең тасвиры;

коррупция җинаятьләренә күндерүнең ысуллары һәм шартлары (сатып алу, янау, алдау һ. б.), шулай да коррупция җинаятьләрен эшләү турында шәхес тәкъдименнән баш тарту (риза булу) турында мәгълүмат;

прокуратура яисә башка дәүләт органнарына (кайсылар) Белдерүнең җибәрү датасы.

5. Гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән кайсыдыр шәхесләрнең мөрәҗәгатенең шартларынраслый торган барлык булган материаллар Белдерүгә кушыла.

6. Белдерү министр (аның бурычларын башкаручы шәхесе) исеменә язылa һәм кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең җитәкче киңәшчесенә (коррупциягә каршылык эше буенча), коррупциячел һәм башка җинаятьләр профилактикасы буенча эш өчен җаваплы шәхескә (алга таба – Җаваплы шәхес) тоткарсыз тапшырыла, ә әгәр билгеләнгән тәкъдим хезмәттән тыш вакытта килгән булса, тоткарсыз хезмәт итү урынына килү мизгеленнән үк.

7. Гражданлык хезмәткәре вазифа (хезмәт) бурычларын башкара тормаган вакытта яисә даими хезмәт урынының чикләрендә булмаганда Белдерү почта җибәрүе, факсимиль элемтә каналлары яисә башка мөмкин электрон элемтә каналлары аша юнәлтелә ала, шуннан соңгы хезмәткә кире кайтуга Белдерүнең оригиналын Җаваплы шәхескә тапшырып.

8. Җаваплы шәхес Белдерүне дәүләт хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкилен белдерүләренең теркәү журналында (алга таба – журнал) Тәртипнең 2 нче кушымтасына карата терки.

9. Белдерүне журналда теркәгәннән соң гражданлык хезмәткәренә кул куюга Белдерүне алган шәхес турында мәгълүматлар һәм Белдерүнең теркәү датасы язылган Белдерү копиясе бирелә. Белдерү почта аша килгән очракта Белдерү копиясе Белдерүне җибәргән гражданлык хезмәткәренә почта аша заказной хат белән җибәрелә.

Белдерү теркәвен кире кагу, шулай да Белдерү копиясен бирмәү ярамый.

10. Алынган мәгълүматларның серлелеге “Шәхси мәгълүматлар турында” 2006 ел 27 нче июль № 152-ФЗ Федераль законының таләпләренә туры китереп тәэмин ителә.

11. Белдерүне теркәү көнендә Җаваплы шәхес аны министрга (аның бурычларын башкаручы шәхесенә) карап тикшерүгә бирә; эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итәр өчен.

12. Министр (аның бурычларын башкаручы шәхесе) эчке эшләр органнарына

яисә башка дәүләт органнарына Белдерүне җибәрү турында карар кабул иткәндә Җаваплы шәхес шундый карарны кабул иткән көннән бирле ике эш көне эченнән соңга калмыйча, материалларны кушып, Белдерү җибәрүен башкара.

13. Коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен, прокуратура органнарын яисә башка дәүләт органнарын белдергән дәүләт хезмәткәре Русия Федерациясе законнарына туры китереп дәүләт яклавы астында тора.

14. Министрлыкның гражданлык хезмәткәре коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү фактлары турында яллаучы вәкилен белдерү бурычын үтәмәү аны дәүләт хезмәтеннән чыгаруга яисә Русия Федерациясе законнарына туры китереп башка җаваплылык төрләренә тарттыруга китерә торган җинаять булып тора.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибенә Кушымта № 1

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры

______________________________________
(Ф.И.О., урнашкан вазифа, структура
______________________________________
бүлекчәсе, тору урынының адресы,
______________________________________
телефон номеры)

БЕЛДЕРҮ
Татарстан Республикасы ГТХМ ның дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү

_______________________________________________________________________
(җинаятькә күндерүче шәхеснең Ф.И.О., вазифасы, аның турында барлык билгеле мәгълүматлар)
ягыннан мине коррупция җинаятенә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында белдерәм.

Җинаятькә күндерү _______________________________________________________
(хезмәткәр ягына шәхес башкарган һәм гражданлык хезмәткәренә килгән
_______________________________________________________________________
мөрәҗәгатьнең (хәрәкәтнең), тәкъдимнең, гаризаның, таләпнең, коррупция җинаятен эшләүгә күндерү турында
_______________________________________________________________________
күрсәтә торган башка формада мөрәҗәгатьнең җентекле тасвиры, шулай да гражданлык хезмәткәрен күндергән
__________________________________________ мин эшләү максаты белән үткәрелде.
җинаятенең билгеләре булган хәрәкәтләрнең тасвиры)

Җинаятькә күндерү _______________________________________________________
(күндерүнең ысулы һәм шартлары, сатып алу, янау, алдау һ. б.,
_______________________________________________________________________
шулай да шәхеснең коррупция җинаятен эшләү турында тәкъдименнән
_____________________________________________________ ярдәме белән эшләнде.
баш тарту (риза булу) турында мәгълүмат)

Җинаятькә күндерү _______________________________________________________
(телефон сөйләшүдә, шәхси очрашуда,
_____________________________________________________________ эшләнде.
смс хат буенча һ. б.)

Җинаятькә күндерү ________ сәгать ________ минутта булды.

Шулай да ______________________________________________________________
(прокуратура органнарын һәм башка
____________________________________________ белдерү турында хәбәр итәм.
дәүләт органнарын (кайсылар) белдурү датасы)

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ______________ | ______________ |
| (дата) | (имза) | (имзаны ачыклау) |

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү факты турында яллаучы вәкилен белдерү тәртибенә
Кушымта № 2

**ЖУРНАЛ**

Татарстан Республикасы ГТХМ да дәүләт гражданлык хезмәткәрен коррупция җинаятьләрен эшләүгә күндерү максаты белән мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкилен белдерүләрнең теркәү журналы

| № т/б | Белдерүне теркәү датасы | Белдерүне тапшыручынын вазифасы., Ф.И.О. | Белдерүне тапшырганның имзасы | Белдерүне теркәгәннең Ф.И.О. | Белдерүне теркәгәннең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |